**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән андый килешүләрне төзү хокукына аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында**

«Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 33 статьясы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын күтәрү һәм аларны күрсәткәндә закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән андый килешүләрне төзү хокукына аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә әлеге Указ белән расланган административ регламентка законнарда каралган очракларда, билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрнең вакытлы бирелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 15 февраль
№ ПУ-169

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның« 15 » февралендәге
ПУ-169 номерлы Указы
белән расланды

**Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән мондый килешүләрне төзү хокукын алу өчен аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән мондый килешүләрне төзү хокукын алу өчен аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентында Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе ( алга таба – Идарә) тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән мондый килешүләрне төзү хокукын алу өчен аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәтен (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәткәндә административ процедураларның һәм административ эшнең сроклары һәм эзлеклелеге, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты билгеләнә.

1.2. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр (алга таба – гариза бирүчеләр) дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар булып тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан күрсәтелә.

Идарә урнашкан урын: 420021, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Идарәнең эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр. Төшке аш вакыты 13.00 дән 13.45кә кадәр.

Идарәнең белешмәләр өчен телефоны: (843) 211-66-94.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Идарәнең рәсми сайты адресы ojm.tatarstan.ru.

Идарәнең электрон почтасы адресы – ojm@tatar.ru.

1.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәге юллар белән алырга мөмкин:

1) дәүләт хакимияте органы актларын өйрәнгәндә;

2) Идарәнең гариза бирүчеләр белән эшли торган бүлмәләрендә урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү турында сурәт һәм текст рәвешендәге мәгълүматтан торган мәгълүмати стендлар аша;

3) «Интернет» челтәре аша:

Идарәнең рәсми сайтында;

«Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (uslugi.tatar.ru);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (gosuslugi.tatar.ru);

4) Идарәгә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефоннан);

5) Идарәгә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре турындагы мәгълүмат Идарәнең хайваннар дөньясы объектларын лицензияләү, дәүләт исәбенә алу, кадастр һәм аларны файдалануны җайга салу бүлеге (алга таба – Бүлек) белгече тарафыннан Идарәнең рәсми сайтында һәм Идарәнең гариза бирүчеләр белән эшли торган бүлмәләрендә урнаштырылган мәгълүмати стендларда урнаштыра.

## II. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы: аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән мондый килешүләрне төзү хокукын алу өчен аукцион оештыру һәм уздыру.

2.2. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан күрсәтелә.

Гариза бирүчеләрдән дәүләт яки муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән шундый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган хезмәтләрне һәм документларны һәм мәгълүматларны алудан кала, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларына мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.3. Аучылык хуҗалыгы килешүен төзү яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту сәбәбе күрсәтелгән, язма рәвештә бирелгән документ дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурияты туу мөмкинлеген дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты:

1) Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга озак вакытка исәпләнгән лицензиясе булган гариза бирүче белән аучылык хуҗалыгы килешүен төзегәндә – гариза теркәлгән көннән 19 календар һәм 30 эш көне;

2) Аукцион нәтиҗәләре буенча аучылык хуҗалыгы килешүен төзегәндә – аукцион уздыру турында хәбәр басылып чыккан көннән кимендә 9 календар һәм 28 эш көне.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәвештә туган мөнәсәбәтләр түбәндәге норматив хокукый актлар белән җайга салына:

Россия Федерациясе Конституциясе (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1996, № 3, 152 ст.; № 7, 676 ст.; 2001, № 24, 2421 ст.; 2003, № 30, 3051 ст.; 2004, № 13, 1110 ст.; 2005, № 42, 4212 ст.; 2006, № 29, 3119 ст.; 2007, № 1, 1 ст.; № 30, 3745 ст.; 2009, № 1, 1, 2 ст.; № 4, 445 ст.; 2014, № 6, 548 ст.; № 30, 4202 ст.);

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 17, 2003. № 46, 4444 ст.; 2004, № 45, 4377 ст.; № 1, 25 ст; 2005 № 1, 10 ст.; 2006 № 52, 5498 ст.; № 1, 21 ст.; 2007 № 17, 1933 ст.; № 50, 6246 ст.; 2008 № 30, 3616 ст.; № 49, 5748 ст.; № 1, 17 ст.; 2009 № 11, 1261 ст.; № 30, 3735 ст.; 2010 № 1, 32 ст.; 2011 № 30, 4590 ст.; № 48 6732, ст.; 2013, № 19, 2331 ст.; 2015, № 29, 4359 ст., 4370 ст.);

«Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 30, 3735 ст. ; № 52, 6441, 6450 ст.; 2010, № 23, 2793 ст.; 2011, № 1, 10 ст.; № 25, 3530 ст. ; № 27, 3880 ст. ; № 30, 4590 ст. ; № 48, 6732 ст. ; № 50, 7343 ст. ; 2013, № 19, 2331 ст. ; № 27, 3477 ст.; № 30, 4034 ст.; № 52, 6961 ст.; 2014, № 52, 6961 ст.; № 42, 5615 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2038 ст.; № 27, 3873 ст.; № 27, 3880 ст.; № 29, 4291 ст.; № 30, 4587 ст.; № 49, 7061 ст.; 2012, № 31, 4322 ст.; 2013, № 14, 1651 ст.; № 27, 3477 ст.; № 27, 3480 ст.; № 30, 4084 ст.; № 51, 6679 ст.; № 52, 6952 ст.; № 52, 6961 ст.; № 52, 7009 ст.; 2014, № 26, 3366 ст.; № 30, 4264 ст.; № 49, 6928 ст.; № 1, 67 ст.; № 1, 72 ст.; 2015, № 10, 1393 ст.; № 29, 4342, 4376 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аучылык хуҗалыгы килешүе төзү хокукына аукцион үткәрмичә аучылык хуҗалыгы килешүе төзегәндә аучылык биләмәсе мәйданының берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2010 елның 30 июнендәге 490 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 27, 3501 ст.; 2013, № 36, 4581 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең дәүләт бюджетныкы булмаган фондлары вазыйфаи затларының, шулай ук атом энергиясе буенча «Росатом» дәүләт корпорациясенең һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр бирү һәм аларны карап тикшерү тәртибе хакында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары

(Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2012, № 35, 4829 ст.; 2014, № 50, 7113 ст.; 2015, № 47, 6596 ст.);

Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 18 апрелендәге 246 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары җыентыгы, 2008, № 19; 2009, № 11-12; 2010, № 22; № 30; 2011, № 5, № 21; № 38; № 40, № 48; 2012, № 38; № 67; 2013, № 26, № 93; 2014, № 33-34; 2015, № 18, № 50-51).

2.6. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге:

1) хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензияләре булган затлар өчен – әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча гариза;

2) аукционда катнашучы затлар өчен:

аукционны оештыручы тарафыннан аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләү таләбе куелган очракта, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында түләнгән акчаны кайтару өчен счет реквизитлары күрсәтелгән, аукционда катнашу өчен билгеләнгән формада бирелгән гариза;

аукционны оештыручы тарафыннан аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләү таләбе куелган очракта, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләнүен раслый торган документлар.

2.7. Норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары карамагындагы һәм гариза бирүченең үз теләге белән тапшырырга хокукы булган документлар исемлеге:

аукционда катнашучы затлар өчен – бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан аукцион уздыру турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясенең сату үткәрү турында мәгълүмат бастыру өчен рәсми сайтында (www.torgi.gov.ru) урнаштырылу көненә кимендә алты ай кала алынган өземтә (бердәм дәүләт шәхси эшкуарлар реестрыннан өземтә) яки аның нотариус раслаган күчермәсе.

Әлеге документлар гариза бирүче тарафыннан Федераль салым хезмәтендә һәм аның территориаль органнарында, шул исәптән ирекле формада язылган гариза урнаштырып, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

2.8. Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив-хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны яки каралмаган гамәлләр кылуны;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру хакында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан кала, Россия

Федерациясе норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив-хокукый актлары һәм муниципаль норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарына караучы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматларны бирүне.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап язылган гаризаны кабул итүдән баш тартуга түбәндәгеләр нигез була:

1) хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга озак вакытка исәпләнгән лицензиясе булган затлар өчен – тапшырган гаризасының билгеләнгән формага туры килмәве;

2) аукционда катнашучы затлар өчен:

әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында каралган документларны бирмәү;

аукционда катнашуга гаризаның аукцион уздыру турындагы хәбәрдә билгеләнгән вакытта бирелмәве;

бу аукционда катнашу өчен гариза бирүченең кабаттан гариза бирүе;

аукцион оештыручының аукцион уздырудан баш тартуы.

2.10. Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензияләре булган затларга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.11. Аукционда катнашучы затларга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) аукционда катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланган көнгә кадәр аукцион уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән счетка аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында түләнгән акчаның килмәве (аукционны оештыручы тарафыннан аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү таләбе куелган очракта);

2) аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның аукцион уздыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яки дөреслеккә туры килми торган мәгълүматлар бирү.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр каралмаган.

2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә аны күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка хезмәтләр күрсәтелми.

2.14. Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензияләре булган затларга дәүләт хезмәте Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аучылык биләмәсе мәйданының бирәмлеге өчен түләү ставкасын (1 га аучылык биләмәсе өчен 10 сум) тиешле аучылык биләмәсе мәйданына тапкырламасы буларак билгеләнә торган түләү бәрабәренә күрсәтелә.

Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензияләре булган һәм Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә урман кишәрлекләрен арендалауга шартнамәләр төзү хокукын сату аукционы йомгаклары буенча аучылык хуҗалыкларын алып бару өчен урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре төзегән затларга дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

Аукционнарда катнашучы затларга дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә чират көтү 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

2.16. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне сораган мөрәҗәгатен теркәү әлеге Административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә гариза кергән көндә башкарыла.

2.17. Гариза бирүчеләр белән эшләү биналарында дәүләт хезмәте күрсәтү турында сурәт һәм текст рәвешендәге мәгълүматтан торган мәгълүмати стендлар урнаштырыла. Бинаның фасад өлешендә Идарәнең атамасы турында мәгълүмат урнаштырыла.

Гариза бирүчеләргә кабул итүне көтеп алу һәм документларны рәсмиләштерү өчен өстәлләр, урындыклар белән җиһазландырылган урыннар бирелә.

Бүлмәләр санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш.

Министрлыкта инвалидларга хезмәт күрсәтү өчен шартлар тудыру зарур: биналар пандуслар, махсус киртәләр һәм култыксалар белән тәэмин ителергә тиеш.

Министрлык бинасына янәшә территориядә транспорт кую өчен урыннар корыла.

2.18. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең аңлаешлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) гаризаны кабул итү һәм карау сроклары үтәлү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

3) Идарәнең дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Административ регламент бозылуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу (Идарәнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына карата прецедентлар, шикаятьләр санының нисбәте).

2.19. Гариза бирүченең Идарә вазыйфаи затлары белән элемтәләре түбәндәгечә башкарыла:

1) документлар биргәндә элемтәләр 15 минуттан да артырга тиеш түгел.

2) аукцион уздырганда элемтәләр – аукцион уздыру дәвамында.

2.20. Дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турындагы мәгълүмат Министрлыкка телдән (шәхсән, вәкил яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан алынырга мөмкин.

2.21. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә күрсәтелми.

## III. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр

### Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кылынган гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы

3.1. Әлеге бүлектә китерелгән административ процедураларның тулы исемлеге:

1) хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензияләре булган зат белән аучылык хуҗалыгы килешүен төзегәндә:

а) хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган заттан гариза кабул итү;

б) хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган затның гаризасын карап тикшерү һәм аучылык хуҗалыгы килешүе проектын рәсмиләштерү;

в) хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган зат белән аучылык хуҗалыгы килешүен төзү;

2) аукцион нәтиҗәләре буенча аучылык хуҗалыгы килешүен төзегәндә:

а) аукцион уздыру турындагы хәбәрне бастырып чыгару;

б) аукционда катнашуга гаризалар кабул итү;

в) аукцион уздыру һәм анда җиңүчене билгеләү (аукционны уздырылмады дип тану);

г) аукционда җиңүче белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү;

д) аукционда бердәнбер катнашучы белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы әлеге Административ регламентның 2 нче кушымтасында бирелә.

### Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган затның гаризасын кабул итү

3.3. Административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып, хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган затның яисә аның тиешле вәкаләтләр бирелгән вәкиленең әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча бирелгән, территорияләрдән һәм акваторияләрдән файдалану турындагы шартнамәләрдә күрсәтелгән аучылык хуҗалыкларына карата аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү турындагы гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать итүе тора.

3.4. Административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып Бүлек башлыгы тора.

3.5. Идарәнең эшләр башкаруны гамәлгә ашыручы белгече:

1) әлеге Административ регламентның 2.9 пунктының 1 пунктчасында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булу (булмауны) тикшерә;

2) документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаса:

гаризаны терки;

гаризаны гариза бирүчегә тапшыра яки почта аша, документларны кабул итү вакытын, документның кабул ителүен белдерүче теркәү номерын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен җибәрә;

гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны Идарә башлыгына җибәрә;

3) документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, гариза бирүчегә гаризаны теркәүдән баш тарту өчен сәбәпләр барлыгы турында хәбәр итә һәм кабул итүдән баш тартуны язма рәвештә нигезләп, документларны кире бирә.

3.6. Әлеге Административ регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән гамәлләр гариза бирелгән көнне үтәлә.

3.7. Гаризаны кабул итү һәм теркәү һәм аны Идарә башлыгына карап тикшерүгә тапшыру яисә документларны кабул итүдән баш тарту һәм аларны гариза бирүчегә кайтару процедура нәтиҗәсе булып тора.

### Гаризаны карап тикшерү һәм аучылык хуҗалыгы килешүе проектын төзү

3.8. Идарә башлыгының теркәлгән гаризаны кабул итүе административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.9. Бүлек башлыгы административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып тора.

3.10. Идарә башлыгы гаризаны карап тикшерүче һәм аучылык хуҗалыгы килешүенең проектын төзүче җаваплы башкаручыны билгели.

3.11. Җаваплы башкаручы:

1) гаризада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерү өчен аучылык хуҗалыгына бара;

2) аучылык хуҗалыгы килешүе проектын ике нөсхәдә әзерли һәм ул имза куйсын өчен Идарә башлыгына җибәрә.

3.12. Әлеге Административ регламентның 3.10 һәм 3.11 пунктларында каралган гамәлләр гариза теркәлгән көннән соң 30 эш көне дәвамында үтәлә.

3.13. Идарә башлыгына ул имза куйсын өчен җибәрелгән, ике нөсхәдә төзелгән аучылык хуҗалыгы килешүе процедура нәтиҗәсе булып тора.

### Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган зат белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү

3.14. Идарә башлыгына ул имза куйсын өчен аучылык хуҗалыгы килешүе проекты кертелү процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.15. Административ процедураның үтәлеше өчен җаваплы зат булып Бүлек башлыгы тора.

3.16. Идарә башлыгы аучылык хуҗалыгы килешүенең ике нөсхәсенә имза куя һәм аларны җаваплы башкаручыга җибәрә.

3.17. Җаваплы башкаручы аучылык хуҗалыгы килешүенең Идарә башлыгы имза куйган ике нөсхәсен аның тапшырылуы турында хәбәр килерлек итеп почта аша заказ рәвешендә гариза бирүчегә җибәрә.

3.18. Гариза бирүче аучылык хуҗалыгы килешүенең ике нөсхәсен тикшерә һәм аларга имза куя, шуннан соң аларны Идарәгә җибәрә.

3.19. Җаваплы башкаручы гариза бирүчедән килгән, ул имза куйган аучылык хуҗалыгы килешүен аучылык хуҗалыгы килешүләре реестрында терки.

3.20. Җаваплы башкаручы аучылык хуҗалыгы килешүләре реестрында теркәлгән аучылык хуҗалыгы килешүенең бер нөсхәсен аның тапшырылуы турында хәбәр килерлек итеп почта аша заказ рәвешендә гариза бирүчегә җибәрә.

3.21. Әлеге Административ регламентның 3.16 пунктында каралган гамәлләр Идарә башлыгына аучылык хуҗалыгы килешүе проекты җибәрелгән көннән соң бер көн эчендә, 3.17 пунктында каралганнары Идарә башлыгы тарафыннан аучылык хуҗалыгы килешүе җаваплы башкаручыга җибәрелгән көннән соң бер көн эчендә, 3.18 пунктында каралганнары аучылык хуҗалыгы килешүе гариза бирүчегә җибәрелгән көннән соң 10 көн дәвамында (вакыт ягыннан таләпнең үтәлеше җаваплы башкаручы тарафыннан тәэмин ителә), 3.19 пунктында каралганнары аучылык хуҗалыгы килешүе Идарәгә җибәрелгән көннән соң биш көн дәвамында, 3.20 пунктында каралганнары аучылык хуҗалыгы килешүе теркәлгән көннән соң бер көн дәвамында башкарыла.

3.22. Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка каралган лицензиясе булган зат белән аучылык хуҗалыгы килешүен төзү административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

Аукцион уздыру турында мәгълүматны бастырып чыгару

3.23. Аучылык хуҗалыгы килешүен төзү хокукы алуга аукцион уздыру административ процедура башлау өчен нигез булып тора.

3.24. Бүлек башлыгы процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып тора.

3.25. Идарә белгече Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге сәүдә уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) аукцион уздыру турында хәбәр урнаштыра.

3.26. Аукцион уздыру турындагы хәбәрнамәгә түбәндәге белешмәләр кертелә:

1) аукционны оештыручы – Идарә турында;

2) аукцион предметы турында, шул исәптән аучылык биләмәсе урнашкан урын, аның чикләре һәм мәйданы, анда урнашкан җир кишәрлекләре һәм урман кишәрлекләре, күрсәтелгән җир кишәрлекләре һәм

урман кишәрлекләрен файдалануга кертелгән чикләүләр, урманнардан һәм башка табигать байлыкларыннан файдалануга кертелгән чикләүләр, аулау параметрлары турында;

3) аукционда катнашу өчен гариза бирү урыны, башлану һәм тәмамлану вакыты һәм аукцион уздыру вакыты (аукционда катнашу өчен гариза бирү вакыты 14 эш көнен тәшкил итә);

4) аучылык биләмәләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен һәм урман кишәрлекләрен арендага биргән өчен иң түбән аренда түләвеннән һәм хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган өчен еллык җыем күләменнән чыгып саналган аренда түләвенең еллык күләме турында;

5) Идарәнең аукцион турында документлар урнаштырылган рәсми сайты турында;

6) җир кишәрлекләрен һәм урман кишәрлекләрен арендага бирү килешүе буенча, иң түбән аренда түләвеннән чыгып саналган, җир кишәрлекләрен һәм урман кишәрлекләрен арендага бирү өчен аренда түләвенең еллык күләме буларак билгеләнә торган, хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган өчен еллык җыемның күләме буларак билгеләнгән аукцион предметының башлангыч бәясе (аучылык хуҗалыгы килешүе төзү хокукының башлангыч бәясе) турында;

7) аукцион нәтиҗәләре буенча аучылык хуҗалыгы килешүе төзелергә тиешле вакыт турында.

3.27. Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге сәүдә уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) аукцион уздыру турында хәбәр урнаштыру белән бергә, аукцион турында хәбәрдә күрсәтелгән белешмәләрдән гайре, аукцион турындагы түбәндәге документлар урнаштырыла:

1) аукционда катнашу өчен гариза рәвешенә һәм эчтәлегенә таләпләр;

2) аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларны кире алу тәртибе һәм вакыты, андый гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

3) «аукцион адымы» (аукцион предметының башлангыч бәясен арттыру күләме, аукцион предметының башлангыч бәясеннән бер процентан алып биш процентка кадәр билгеләнә);

4) аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү өчен түләнгән акчаның күләме, тиешле акчаны түләү вакыты һәм тәртибе, оештыручы тарафыннан аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләү таләбе куелган очракта, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында түләнгән акчаны күчерү өчен счет реквизитлары;

5) гариза бирүче аукционда җиңүче дип танылган очракта, аучылык хуҗалыгы килешүе төзү хокукын алыр өчен, ул акча күчерергә тиешле счет реквизитлары, әлеге акчаны күчерү вакыты һәм тәртибе;

6) аучылык хуҗалыгы килешүе проекты;

7) аукцион нәтиҗәләре буенча, аучылык биләмәләре чикләрендә урнашкан һәм дәүләт милкендә булган (әгәр мондый җир кишәрлекләре һәм

урман кишәрлекләрен файдалану Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан башкарылса) җир кишәрлекләре һәм урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре төзелергә тиешле вакыт турында белешмә.

3.28. Әлеге Административ регламентның 3.25 һәм 3.27 пунктларында каралган гамәлләр аукцион уздырылу көненә кимендә 25 көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

3.29. «Интернет» челтәрендә аукцион уздыру турында хәбәр һәм аукцион документларын урнаштыру процедураның нәтиҗәсе булып тора.

Аукционда катнашу өчен гаризаларны кабул итү

3.30. Аукционда катнашуга гариза бирү датасы җитү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.31. Бүлек башлыгы процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып тора.

3.32. Аукционда катнашу өчен гариза бирүче Идарәгә шәхсән үзе яки үзенең вәкаләтле вәкиле аша яисә почта аша аукцион үткәрү турында хәбәрнамәдә билгеләнгән вакытта түбәндәге документларны тапшыра:

1) аукционны оештыручы тарафыннан аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләү таләбе куелган очракта, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында түләнгән акчаны кайтару өчен счет реквизитлары күрсәтелгән, аукционда катнашу өчен билгеләнгән формада бирелгән гариза (алга таба – гариза);

2) аукционны оештыручы тарафыннан аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләү таләбе куелган очракта, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләнүен раслый торган документлар.

гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән булырга тиеш.

3.33. Гариза бирүче бары бер гариза гына бирергә хокуклы.

3.34. Бүлек белгече:

1) әлеге Административ регламентның 2.9 пунктының 1 пунктчасында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.11 пунктында каралган нигез булмаган очракта, гаризалар кабул итү беркетмәсенә гариза бирүче турында, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаны тапшыру вакыты турында, аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында акча түләнүе турында белешмәләрне кертә;

2) әлеге Административ регламентның 2.9 пунктының 1 пунктчасында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның

2.11 пунктында каралган нигез булса, гариза бирүчегә, кабул итүдән ни өчен баш тартуны нигезләп, аның гаризасын кире кайтара һәм гаризалар кабул итү беркетмәсенә аукционда катнашуга рөхсәт бирелмәгән гариза бирүче турында, аңа ни өчен аукционда катнашырга рөхсәт бирелмәве сәбәпләрен күрсәтеп, белешмәләр кертә.

3.35. «Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Бүлек белгече дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан, әгәр гариза бирүче тиешле документы мөстәкыйль рәвештә бирмәгән булса, юридик затларга кагылышлы рәвештә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә шәхси эшкуарларга кагылышлы рәвештә шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратып ала, ә дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы соратылган мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә бирә.

3.36. Аукционда катнашуга бирелгән гаризалар кабул итү беркетмәсенә Идарә башлыгы имза куя. Аукционда катнашуга бирелгән гаризалар кабул итү беркетмәсенә имза куелган вакыттан гариза бирүче аукционда катнашучыга әйләнә.

3.37. Бүлек белгече аукционда катнашучы дип танылган гариза бирүчеләргә һәм аукционда катнашуга рөхсәт бирелмәгән гариза бирүчеләргә аукционда катнашуга бирелгән гаризалар кабул итү беркетмәсе белән рәсмиләштерелгән, кабул ителгән карар турында хәбәр бирә.

3.38. Аукционда катнашуга рөхсәт бирелмәгән гариза бирүчегә аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында түләнгән акчасы кире кайтарыла.

3.39. Әлеге Административ регламентның 3.34 пунктының 1 пунктчасында каралган гамәлләр гариза кергән көнне, 3.34 пунктының 2 пунктчасында каралган гамәлләр гариза кергән көнне (әлеге Административ регламентның 2.9 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булса) яисә аукционда катнашуга бирелгән гаризалар кабул итү беркетмәсенә имза куелган көннең киләсе көненнән дә соңга калмыйча (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.11 пунктында каралган нигез булса), 3.35 пунктта каралганнары документлар кабул ителгән вакыттан гаризаны җибәрү өлешендә бер эш көне эчендә һәм мәгълүматлар бирү өлешендә гариза алынган көннән соң биш көн эчендә, 3.36 пунктында каралганнары гаризалар кабул итү вакыты тәмамланган көннән алып бер көн дәвамында, 3.37 пунктында каралганнары аукционда катнашуга бирелгән гаризалар кабул итү беркетмәсенә имза куелган көннең киләсе көненнән дә соңга калмыйча, 3.38 пунктында каралганнары аукционда катнашуга бирелгән гаризалар кабул итү беркетмәсен рәсмиләштерү көненнән соң биш эш көне дәвамында үтәлә.

3.40. Аукционда катнашуга рөхсәт бирү яисә аукционда катнашуга рөхсәт бирмәү турындагы карар кабул итү административ процедураның нәтиҗәсе була.

Аукцион уздыру һәм җиңүчене билгеләү (аукцион уздырылмады дип тану)

3.41. Административ процедураны башлау өчен, аукцион уздыруның вакыты килеп җитү нигез булып тора.

3.42. Бүлек башлыгы процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып тора.

3.43. Бүлек бүлеге:

1) аукцион предметы бәясенә кагылышлы соңгы һәм аңа кадәрге тәкъдимнәр күрсәтелгән аукцион беркетмәсен алып бара;

2) аукционны аудио- һәм видеотасмага яздыра;

3.44. Аукционны уздыруда катнашучы теләсә кайсы зат аукционны аудио- һәм видеотасмага яздыра ала.

3.45. Аукцион аның предметының башлангыч бәясен (аучылык хуҗалыгы килешүен төзү хокукына башлангыч бәяне) «аукцион адымы»на күтәрү юлы белән уздырыла.

3.46. Аучылык хуҗалыгы килешүен төзү хокукына иң югары бәя тәкъдим иткән аукционда катнашучы аукционда җиңүче дип табыла.

3.47. Аукцион түбәндәге очракларда узмаган дип таныла:

1) аукционда катнашучыларның саны икедән дә ким булса;

2) аукцион предметының башлангыч бәясен өч тапкыр игълан иткәннән соң, аукционда катнашучыларның берсе дә аукцион предметын башлангыч бәядән сатып алу ниятен белдермәсә.

3.48. Аукцион нәтиҗәләре Идарә башлыгы һәм аукционда җиңүче имза куйя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмә ике нөсхәдә тутырыла, шуларның берсе аукционда җиңүчегә тапшырыла, икенчесе Идарәдә кала.

3.49. Бүлек белгече аукционда җиңүчегә ул өстәмә түләргә тиешле бәя турында ( аучылык хуҗалыгы килешүе төзү хокукының бәясе белән алдан түләгән бәянең аермасы) хәбәр итәргә тиеш. Аукционда җиңүче аны, аукцион документларында күрсәтелгән вакыт эчендә, исәп-хисап счетына күчерергә тиеш.

3.50. Бүлек белгече аукционда катнашып та, анда җиңеп чыкмаган затларга аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның ышанычлы булуын тәэмин итү сыйфатында түләнгән акчаны кире кайтаруны тәэмин итә.

3.51. Бүлек белгече Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге сәүдә уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра.

3.52. Әлеге регламентның 3.43 һәм 3.48 пунктларында каралган гамәлләр аукцион уздырылган көндә, 3.49 пунктында каралганнары аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә имза куелган көннән өч эш көне дәвамында, 3.50 пунктында каралганнары аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә имза куелган көннән биш эш көне дәвамында, 3.51 пунктында каралганнары

аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә имза куелган көннән өч эш көне дәвамында башкарыла.

3.53. Аукционда җиңүчене (җиңүчеләрне) ачыклау яисә аукционны уздырылмады дип тану административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

Аукционда җиңүче белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү

3.54. Административ процедураны башлау өчен нигез булып аукционда җиңүчене ачыклау тора.

3.55. Процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып Бүлек башлыгы тора.

3.56. Аучылык хуҗалыгы килешүе аукционны уздыру турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән шартлар буенча төзелә. Аучылык хуҗалыгы килешүен төзегәндә һәм үтәгәндә ике якның килешүе буенча яки бер як таләбе буенча аукцион шартларын үзгәртү тыела.

3.57. Аукционда җиңүче аукцион турында документларда күрсәтелгән исәп-хисап счетына әлеге Административ регламентның 3.49 пунктында каралган өстәмә түләү кертергә тиеш.

3.58. Бүлек белгече ике нөсхәдә аучылык хуҗалыгы килешүе төзи һәм аны Идарә башлыгына кул куярга бирә.

3.59. Идарә башлыгына ике нөсхәдә аучылык хуҗалыгы килешүенә кул куя һәм аны Бүлек белгеченә җибәрә.

3.60. Бүлек белгече Идарә башлыгы тарафыннан кул куелган ике нөсхәдә аучылык хуҗалыгы килешүен кулга тапшырылу турындагы хәбәрнамә белән почта аша гариза бирүчегә җибәрә.

3.61. Гариза бирүче аучылык хуҗалыгы килешүен карый һәм ике нөсхәдә килешүгә кул куя, шуннан соң аны Идарәгә җибәрә.

3.62. Бүлек белгече гариза бирүче тарафыннан кул куелган аучылык хуҗалыгы килешүен аучылык хуҗалыгы килешүләре реестрында терки.

3.63. Бүлек белгече аучылык хуҗалыгы килешүләре реестрында теркәлгән аучылык хуҗалыгы килешүенең бер нөсхәсен кулга тапшырылу турындагы хәбәрнамә белән почта аша гариза бирүчегә җибәрә.

3.64. Аукционда җиңүче аучылык хуҗалыгы килешүен төзүдән баш тарткан очракта, Идарә, аукционда җиңүченең әлеге килешүне төзүдән баш тарту нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауны сорап, судка мөрәҗәгать итәргә яисә аукцион предметына бәя турында иң соңгы тәкъдимне ясаган аукционда катнашучы (аучылык хуҗалыгы килешүен төзү хокукына бәя биргән) белән шундый килешү төзергә хокуклы.

3.65. Әлеге Административ регламентның 3.57 – 3.63 пунктларында каралган гамәлләр аукцион турында белдерү кәгазендә һәм аукцион документларында күрсәтелгән срокларда уздырыла, ләкин Россия Федерациясенең сату уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (torgi.gov.ru) аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 10 көн узгач тәмамланырга тиеш.

3.66. Административ процедура нәтиҗәсе булып, аукционда җиңүче белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү тора.

Аукционда бердәнбер катнашучы белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү

3.67. Административ процедураны башлау өчен нигез булып әлеге Административ регламентның 3.47 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән сәбәпләр буенча аукционны узмаган дип тану тора.

3.68. Процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып Бүлек башлыгы тора.

3.69. Аучылык хуҗалыгы килешүе аукцион уздыру турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән шартлар буенча төзелә. Аучылык хуҗалыгы килешүен төзегәндә һәм үтәгәндә ике якның килешүе буенча яки бер як таләбе буенча аукцион шартларын үзгәртү тыела.

3.70. Аучылык хуҗалыгы килешүен әзерләү һәм аңа кул кую әлеге Административ регламентның 3.58 – 3.63 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә тормышка ашырыла.

3.71. Әлеге Административ регламентның 3.70 пунктында каралган гамәлләр аукцион узган көннән 30 көн дәвамында тормышка ашырыла, ләкин Россия Федерациясенең сату уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (torgi.gov.ru) аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 10 көн узгач тәмамланырга тиеш.

3.72. Административ процедура нәтиҗәсе булып, аукционның бердәнбер катнашучысы белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү тора.

IV. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү формалары

4.1. Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларны үтәүгә һәм башкаруга агымдагы контроль, ә шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне тикшерү тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Идарәнең эшләр идарәчесе тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контроль Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны тикшерү юлы белән башкарыла.

Агымдагы контроль даими нигездә тормышка ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль тикшерүләр уздыруны, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклауны һәм бетерүне, гариза бирүчеләрнең Идарәнең вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләрен карауны, алар буенча карарлар кабул итү һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

4.4 Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү Идарә актлары нигезендә башкарыла.

Тикшерүләр планлы рәвештә (Идарәнең яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Административ регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозуларның элек ачыкланган очракларын бетерүне тикшерү;

2) гражданнарның, юридик затларның Идарәнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлары гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларга шикаятьләре белдергән мөрәҗәгатьләре.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган кимчелекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр билгеләнә.

4.7. Контроль уздыру нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту тормышка ашырыла.

4.8. Гариза бирүчеләр, гражданнар, юридик затлар, шәхси эшкуарлар ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүгә тикшерү, Административ регламентта каралган мәгълүматны алу юлы белән, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәткәндә алар тарафыннан кабул ителгән карарларга вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү юлы белән башкарыла.

## V. Идарәнең, аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында эшләнгән (карар чыгарылган) һәм әлеге Административ регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтү таләпләрен урнаштыручы, башка хокукый норматив актларның таләпләрен боза торган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

5.2. Судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып, Идарәнең, аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарлар тора.

Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы үтәлмәү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы үтәлмәү;

3) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, әлеге Административ регламент белән билгеләнмәгән документлар таләп итү;

4) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, әлеге

Административ регламент белән билгеләнгән документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнмәгән нигезләр буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, әлеге Административ регламент белән билгеләнмәгән түләү таләп итү;

7) Идарәнең, шулай ук аның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә әлеге төзәтмәләрне кертү вакыты үтәлмәү.

5.3. Шикаять Идарәгә кертелә. Идарә башлыгы тарафыннан кабул ителгән карарга шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә.

5.4. Шикаять бирүчене шәхси кабул иткәндә шикаять язма рәвештә яисә электрон рәвештә бирелә.

5.5. Шикаять гариза бирүче вәкиле тарафыннан бирелгән очракта, шулай ук гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкаруга вәкаләтләрне раслаучы документ та таләп ителә. Гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкаруга вәкаләтләрне раслаучы документ итеп Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч язуы бирелә ала.

5.6. Язма рәвештә шикаятьләр Идарә тарафыннан эш сәгатьләрендә кабул ителә.

Язма рәвештә шикаять почта аша җибәрелергә мөмкин.

Шәхси кабул итү вакытында шикаять биргән очракта, гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.

5.7. Гариза бирүче электрон рәвештә шикаятьне түбәндәгеләр аша бирә ала:

1) Идарәнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты;

2) Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы;

3) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы;

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кабул иткән карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) «Интернет» челтәрен файдаланып, судка кадәрге һәм (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмати системасы.

5.8. Шикаять электрон рәвештә бирелгәндә, әлеге Административ регламентның 5.5 пунктында күрсәтелгән документлар Россия Федерациясе законнары белән каралган төрдә электрон имза куелып, электрон

документлар рәвешендә бирелергә мөмкин, бу очракта гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ таләп ителми.

5.9. Шикаятьне гариза бирүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша бирергә мөмкин. Шикаять кергәннән соң КФҮ аны МФҮ белән Идарә арасында хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин шикаять кергән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, аны карауга вәкаләтле органга җибәрелүен тәэмин итә.

5.10. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмаулары) шикаять белдерелә торган Идарәнең атамасы, Идарәнең тиешле вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә вазыйфасы;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат, элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрергә тиешле электрон почта (булганда) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

3) Идарәнең, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт граждан хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең Идарәнең, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт граждан хезмәткәрләренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Гариза бирүче үзенең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләрен бирергә мөмкин.

5.11. Идарәгә кергән шикаять кергән көннән икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлә һәм 15 эш көне дәвамында шикаятьләрне карарга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш, ә гариза бирүче тарафыннан Идарәнең, аның вазыйфаи затларының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына яки андый хаталарны төзәтү вакыты үтәлмәүгә шикаять биргән очракта – теркәлгән көннән алып, биш эш көне дәвамында карала.

5.12. Шикаятьне карауны туктату өчен нигезләр юк.

5.13. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Идарә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү, шул исәптән кабул ителгән карарның гамәлен туктату, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә норматив хокукый актлар белән каралмаган нигездә түләтелгән акчаларын кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка төрле формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.14. Әлеге Административ регламентның 5.13 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә аның шикаятен карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.15. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 5.63 статьясында каралган административ хокук бозу составы яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, әлеге Административ регламентның 5.3 пункты нигезендә шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат тиз арада булган материалларны прокуратурага җибәрә.

5.16. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавапта түбәнге мәгълүмат күрсәтелә:

1) дәүләт хезмәте күрсәткән, шикаятьне караган орган атамасы, аның шикаять буенча карар чыгарган вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) кабул ителгән карарның номеры, датасы, теркәлгән урыны, шулай ук гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче вазыйфаи зат турында мәгълүмат;

3) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

4) шикаять буенча карар чыгару өчен нигез;

5) шикаять буенча кабул ителгән карар;

6) шикаять нигезле дип саналган очракта – ачыкланган хокук бозуларны бетерү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү вакыты;

7) шикаять буенча чыгарылган карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

5.17. Шикаять буенча бирелгән җавап Идарәнең шикаятьләр карауга вәкаләтле зат тарафыннан имзалана.

5.18. Гариза бирүче, шикаятьне карау барышында Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән карар белән канәгать булмаган очракта, яисә карар чыгарылмаган очракта, гариза бирүче Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итәргә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә судка шикаять бирергә хокуклы.

5.19. Гариза бирүче шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алырга хокуклы.

5.20. Шикаять бирү һәм карау тәртибе турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Идарәнең гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәсендә урнаштырылган шикаять бирү һәм аны карап тикшерү тәртибе турында сурәт һәм текст рәвешендә мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Идарәнең рәсми сайтында;

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында;

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында;

3) Идарәгә телдән мөрәҗәгать итеп (телефон аша яки шәхсән);

4) Идарәгә язмача мөрәҗәгать итеп (шул исәптән, Идарәнең рәсми сайты аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә).

5.21. Идарә түбәндәге очракларда шикаятьне хәл итүдән баш тарта:

1) шул ук предмет турында һәм шул ук нигезләрдә бирелгән шикаять буенча үз көченә кергән суд карары булу;

2) шикаятьнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә вәкаләте расланмаган зат тарафыннан бирелүе;

3) шул ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан һәм шул ук предмет буенча бирелгән шикаять буенча кабул ителгән карар булуы;

4) законнарда каралган башка очракларда.

5.22. Идарә түбәндәге очракларда шикаятьне җавапсыз калдыра (бу турыда билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итүчегә, әгәр аның фамилиясен һәм почта адресын укып булса, хәбәр итә):

1) шикаятьтә цензурасыз һәм кимсетүле сүзләр булу, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә куркыныч янау;

2) шикаятьнең текстын, мөрәҗәгать итүченең фамилиясен яисә почта адресын уку мөмкин булмау.

---

Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән андый килешүләрне төзү хокукына аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе башлыгына

____________________________________

**Аучылык хуҗалыгы килешүен төзү хокукына аукцион уздырмыйча, аучылык хуҗалыгы килешүен төзүгә**
**ГАРИЗА**

____________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(юридик затның тулы исеме, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Сездән, юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга хайваннар дөньясыннан файдалану өчен кирәкле территорияләрне, сулыкларны бирү өчен 20____ елның «____»____________ төзелгән шартнамәдә күрсәтелгән ____ гектар мәйдандагы аучылык биләмәләренә карата, гаризага теркәп бирелә торган чикләрдә, _______ елга, аучылык ресурсларының һәм рөхсәт ителгән ауның түбәндәге төрләренә аучылык хуҗалыгы килешүе төзүне сорый. Хайваннар дөньясыннан файдалану _________ номерлы __________ серияле Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга хокук озак вакытка исәпләнгән лицензия нигезендә барлыкка килде.

| | |
|---|---|
| Аучылык ресурслары турында мәгълүмат: | ________________<br>________________<br>________________ |
| Рөхсәт ителгән ау төрләре турында мәгълүмат: | ________________<br>________________<br>________________ |
| Гариза бирүче турында мәгълүмат (җитәкченең вазыйфасы һәм исем, фамилиясе, атасының исеме, банк реквизитлары, почта адресы, электрон адрес, элемтә өчен телефон): | ________________<br>________________<br>________________<br>________________<br>________________ |

Җитәкче ____________________ ____________________
Имза Ф.И.А.и.

Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе тарафыннан «Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү, шул исәптән андый килешүләрне төзү хокукына аукцион оештыру һәм уздыру» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы

Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка исәпләнгән лицензиясе булган заттан гариза кабул итү

↓

Гаризаны карау һәм аучылык хуҗалыгы килешүе проектын рәсмиләштерү

↓

Хайваннар дөньясыннан файдалануга озак вакытка исәпләнгән лицензиясе булган зат белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү

Аукцион уздыру турында мәгълүматны бастырып чыгару

↓

Аукционда катнашуга гаризалар кабул итү

↓

Аукционны уздыру һәм анда җиңүчене билгеләү (аукционны узмаган дип тану)

↓ Аукционда җиңүче белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү

↓ Аукционда бердәнбер катнашучы белән аучылык хуҗалыгы килешүе төзү